*Йолдыз*

# КОЛАКЛЫ КОЙМАКЛАР



Казан
Татарстан китап нәшрияты
2003

УДК 820/89 (470)
ББК 84 (2 Рос=Тат)–5
Й 68

Кече яшьтәге мәктәп балалары өчен

Рәссамы *Йосыф Вәлиәхмәтов*



**Йолдыз**

Й 68 Колаклы коймаклар: Шигырьләр.— Казан: Тат.кит.нәшр., 2003.— 63 бит.

ISBN 5–298–01348–1

©Татарстан китап нәшрияты, 2003

# Безнең өйдә





## Рамазан аенда

Кояш баер вакыт җитсә,
Йөгерәбез тыз да быз.
Тизрәк авыз ачсын, диеп,
Әбигә әзлибез тоз.
Әби рамазан аенда
Көн буе ризык капмый.
Ничек ачтан үлмидер ул?
Шуңарга җавап тапмыйм.
Чәйне бик тә яратса да,
Түзә, эчмичә тора,
Ашамый-эчми, гел укый
Авыз эченнән дога.
Шуңа кояш баеганны
Без бергәләп көтәбез.
Әби ничектер, ә без
Көтеп арып бетәбез.

Тозны алып бирү белән
Әби аркадан сөя.
— Рәхмәтләр яусын, савабы
Сезгә дә булсын,— дия.
Әбием авыз ачканда,
Җанда рәхәт тоябыз.
Әби белән бергәләшеп
Без дә савап җыябыз.



## Әби хәйләсе



Үзем укый белмәсәм дә,
Мин әкият яратам.
— Сөйлә, сөйлә инде,— диеп,
Әбине аптыратам.
Ул таба берәр хәйлә.
Мине белми ди мәллә?
Әнә диванда ята.
— Юк,— ди,— тешем авырта.
Нигә ялганлый мине
Әбием инде бигрәк...
Әкиятне сөйләргә
Теш түгел бит, тел кирәк.
Аның теле сызламый,
Авырта бары теше.
Әкият сөйләргә тиеш ул
Дәү әни булган кеше.

# Әни сүзе

Әни безгә еш кына:
«Зоопаркка илтәм»,— ди.
Энем риза: «Әйдә соң,
Булмадык бик күптән»,— ди.

Әни әйтә: «Бер илтсәм,
Тиз генә алып кайтмам.
Зоопарк җәнлекләренә
Охшаган сез бар яктан.

Әтәчләр күк сугышасыз,
Ду килеп, өй туздырып,
Хәтта кыланасыз,— ди ул,—
Маймылны да уздырып.

Ә хәйләгә килгәндә,
Төлкене дә җиңәсез.
Киреләнергә дигәндә,
Дәү мөгезле кәҗә сез.

Шуңа зоопаркка илтсәм,
Бик тә теләп алырлар.
Әле алай гынамы соң!
«Рәхмәт» әйтеп калырлар!»

Әни безгә шулай дия,
Беләм инде, шаярта.
Бездән башка нишләсен соң,
Ул бит безне ярата.

Шаяннар, шуклар булсак та,
Түгел аңа без артык.
Ә шулай да җиткәндер шул,
Кеше булырга вакыт.

## Кыскартканнар

Әллә нигә ошамаган —
Әнине кыскартканнар.
Иртәгедән эшкә бармый —
Эшне кыска тотканнар.

Әби елый: «Моннан ары
Яшәрбез ничек итеп?»
Әниемнең үзенең дә
Бүген кәефе китек.

Өйдә барсы да борчулы,
Миннән башка һәммәсе.
Эчемнән генә сөенәм —
Бар бер нәни хәйләсе.

Әни эшкә бармагач,
Булыр гел минем белән.
Мин менә шуны беләм —
Рәхәт ул әни белән!

Белмим, нигә ошамаган —
Әнине кыскартканнар.
Эшендә кыскартканнар,
Ә миңа озайтканнар.

## Өйрәтә

Ни әйтсәм, шуны кабатлый
Энем авыз эченнән.
Ә кычкырып сөйләшергә
Килми әле көченнән.
Чөнки нәни шул әле,
Ике яшь тә тулмаган,
Шуңа аның теле дә
Сөйләшерлек булмаган.
Тагын чак кына үссен дә
Сөйләшер ул кирәктә.
Хәзер энем телен шулай
Сөйләшергә өйрәтә.
Кем белер өйрәнмичә,
Тыңлагыз сез көлмичә.

# Әйбәт укучы булам

Юк, булмас, дип көлмәгез,
Мактанчык та димәгез,
Мин мәктәпкә баргач та,
Әйбәт укучы булам.
Беләм дисезме кайдан
Бу хакта шулай алдан?
Чөнки мине быел ук
Тилмертәләр укытып.
Кич җитүгә көн саен
Кулга әлифба алам,
Кирәкле битне табам.
Башта укыйм хәрефләп,
Бик тырышып, шәрехләп.
Аннан укыйм иҗекләп,
Аннары укыйм сүзләп.
«Ничек өйрәнә?» — диеп,
Әти диванда утыра,
Гәзит артыннан күзләп.
Башта укыйм әтигә,
Аннан укыйм әнигә,
Кабат укыйм әбигә,
Хәтта энем — бәбигә.
Безнең өйдә алты кеше,
Алты кат укыйм, димәк.
Әйбәт укучы булырга
Инде тагын ни кирәк?!





## Язилә

Җәй көне дә бездә яз,
Көз көне дә бездә яз,
Кыш көне дә бездә яз,
Бездә һәрчак көн аяз.
Сеңелемнең исеме
Бик матур шул: Язилә.
Язилә бер елмайса,
Өебезгә яз килә.
Хәтта елавы аның
Ләйсән яңгыр шикелле.
Нәни Язилә сеңлем
Язлар кебек сөйкемле.
Яз кызы өебездә,
Һәрчак яз шуңа бездә.



# Билге

Укырга кердем быел,
Билге бәясен беләм —
Сумка тулы шатлык кайта
Өйгә «бишле»ләр белән.
Билге куям мин үзем
Өйдәгеләр эшенә:
Әби һәрчак «бишле» ала
Пешергән бәлешенә.
Энекәшемнең тәртибе
«Өчле»гә тарта чак-чак —
Киреләнә, үзсүзләнә,
Тыңламый шул ул кайчак.
Әти белән әнинең дә
Барлык билгесе «бишле» —
Алар эштә дә эшлиләр,
Өйдә дә бөтен эшне.
«Бишле» алсаң, син — көчле,
«Бишле» түгел ул «өчле»,
Ләкин белмим үземә
Нинди билге тиешне.
Аны белә тик әти,
Әмма әлегә әйтми.
Ышаныгыз сүземә:
Кыен гына икән ул
Билге кую үзеңә.



## Иҗекләп укыйбыз

Әби укый «Әлифба»,
Мин дә укыйм «Әлифба».
Һәр кич саен кабатлыйбыз:
Монысы «А» да, монысы — «Ба»
Мин укыймын алдыннан,
Әби укый артыннан.
Ул китапны ерак тота,
Мин укыймын якыннан.
Әби гарәпчә өйрәнә,
Мин өйрәнәм үз телем.
Әби әйтә: «Артык булмый
Беркайчан да аң-белем».
Кич җиттеме, кабатлыйбыз
«Та» да, «Са» да, «Фа» да, «Ба».
Миңа — алты, аңа — алтмыш,
Өйрәнәбез «Әлифба».
Ул миңа укып күрсәтә,
Ә мин укыймын аңа.
Шушылай итеп өйрәнгәч,
Хәтердә яхшы кала.
Минем алда әбиемнең
Сер бирәсе ник килсен?
Шуңа тырышып укый ул
«Әлифба»сын — дәресен.
Миңа да әби алдында
Белми утыру — оят.
Сынатасым килмәгәнгә
Укыймын кабат-кабат.
Әбием мактап та куйса,
Башларым күккә тия.
Парлап укуның файдасы
Икебезгә дә тия.

# Бабай кайтты

Бабай кайтты!
Бабай кайтты!
Әй, шатландык,
Аңлату мөмкин түгел.
Бабаем кайтканга күрә,
Бер җырлады,
Бер елады күңел.
Минем аны моңарчы
Юк иде гел күргәнем.
Аның да мине җитәкләп
Юк иде шул йөргәне.
Мин бит аны бик сагындым,
Күп сөйлисе сүзләрем.
Аныкына охшаган ди
Минем зәңгәр күзләрем.
Шулайдыр шул, охшагандыр,
Ул бит минем бабаем.
Бабаемның улы — әти,
Ә мин аның малае.
Бабай кадәр бабай кайткач,
Сөенмисең ди ничек?!
Җитмәсә бит кайткан бабам,
Утлар һәм сулар кичеп.
Ил сакларга киткән булган
Июньнең ал таңында.
Инде менә кайтты,
Кайтты бөтенләйгә.
Тик... «Хәтер китабы»нда.

# Энем теле

Урамда күп уйнадык,
Керик диеп уйладык.
Урамнан кердебез[1] дә,
Һай, җылы өебездә.
Фифитырымны[2] салдым,
Күлмәкчән генә калдым.
Ә күлмәгем кашмаклы[3]
Яшел, каралы, аклы.
Әни ашарга дәште,
Һәм калаклар[4] өләште.
Точмак[5] бик тәмле булган —
Әнием минем уңган.
Аннан йокларга яттык
Өскә ябынып юнган[6].
Кунакка килгән апага
Энем яңалык сөйли.
Апа татарча шәп белә,
Ә энем телен белми.
Нәни шул әле энем.
Тукта, апа, көлмәче,
Энекәшемнең теленә
Мин булам тәрҗемәче.



---

[1] *Кердебез* — кердек.
[2] *Фифитыр* — свитер.
[3] *Кашмаклы* — шакмаклы.
[4] *Калак* — кашык.
[5] *Точмак* — токмач.
[6] *Юнган* — юрган.



## Әби кайда?

Әби кунакка китте,
Бик озакка, бер айга.
Энем моны ишеткән дә
Кич саен карый айга.
Карый, карый,
Тәмам арый,
Чыланганнар күзләре.
Үпкәледер сүзләре:
Әби, әби… юк айда,
Йә, әйтегез, ул кайда?
Айга дисез үзегез,
Ялган бөтен сүзегез.
Әти, әни, берегез,
Әбиемне хет кайдан
Тизрәк табып бирегез!

# Үпкә

Үпкәләдем әнигә.
Үпкәләдемме нигә?
Санламады үземне.
Ярый, үзем түземле.
Миндәй әйбәт малаен,
Куша-куша «ай-ваен»,
Әрләп торган була бит.
Моңа күңел тула бит.
Янәсе, мин бик кире,
Янәсе, мин бик ялкау.
Аңлый алмыйм ни өчен
Миңа соң мондый «мактау»?
Бер тыңламаган өчен
Әрлиләрме шулкадәр?
Бу чаклы мактамас иде,
Тыңлаган булсам әгәр.
Җитмәсә, әнинең сүзен
Күрше кыз да ишеткән.
Мин үзем дә аны күрдем
Коймадагы тишектән.
Ялкау түгеллегемне
Исбатлыйм ничек итеп?
Шуңа күрә үпкәләдем,
Шуңа күңелем китек,
Шуңа җанымда үпкә.
Әмма бердәнбер әнигә
Үпкәләп булмый озакка,
Үпкәләп булмый күпкә.



# Урынсызга әрләмә

Әни мине битәрли:
«Җыйнаксыз»,— диеп әрли.
Әни юкка орыша,
Мин энем дип тырышам.

Ничек дисезме алай?
Энем бар, нәни малай.
Тәпи йөри белми әле,
Егылырга өйрәнгән.
Беркөн әнә егылган да
Тезен, терсәген бәргән.
Шуңа күрә калдырам мин
Бар нәрсәне идәндә:
Күлмәк анда, оек монда...
Энем катыга төшмәсен,
Борыны да канамасын,
Тезбашы да шешмәсен.

Әнә бит еламады,
Егылды шул оекка.
Әгәр идәнгә егылса,
Булмас иде тыеп та.
Шуңа күрә: «Җыйнаксыз»,— дип,
Әрләмә син, әнием.
Җыйнаклыга әйләнәм мин,
Чак кына үссен энем.



# Көтәмен

— Әни, китап укы әле?
— Ярар, улым, эш беткәч.
Вакыты да акрын уза,
Әллә юри, мин көткәч.

— Әни, урамга чыгыйкчы?
— Хәзер, улым, эш бетә.
— Ташла инде, әни, эшең,
Безне бит уен көтә.

— Әни, ашыйсым да килә...
— Хәзер кер генә юам.
Менә бетә, ә син, улым,
Куяның белән юан.

Кер юыла, үтүкләнә.
Ашлар да пешеп чыга.
Әнием мине юата:
— Аз калды, улым, чыда.

Түзәм инде, көтәмен.
Әрәм китмәс көткәнем.
Шундый озак көткәнмен,
Инде йоклап киткәнмен.
Эше беткәндер диеп,
Шатланып та сөенеп,
Уянып күзем ачсам,
Әнием өстәл янында
Токмачка камыр баса.
Нигә инде әниләрнең
Эшләре бик күп икән?
Үзем булышып карасам,
Ул эшләр бетмәс микән?

## Курку

Әни: «Кулыңны ю!» — дигәч,
Тыңлады әле энем.
Тик юыну бүлмәсеннән
Елап чыкты: «Әнием!»
— Ни булды? — диеп сорыйбыз
Төрлебез төрле яктан.
Һәммәбез дә телсез калдык
Көтелмәгән җаваптан.
— Кулымны юдым, сөртергә
Сөлгегә буем җитми,
Сөртмәгәч бит, кул кипми,
Ә кипмәгәч, тутыга...
Елыймын менә шуңа.
Тутыккан куллы малай
Буласым килми минем.
Сөлгене генә, зинһар,
Алып бирче, әнием.



## Бүләк

Кыш бабайдан быел бүләк
күп булды.
Тәмле-тәмле конфет белән
кесәләр тулды.
Матур-матур уенчыклар
бүләк итте ул.
Һәммәбезне сөендерде,
инде китте ул.
Бүләкләрнең куанычы
озакка җитте.
Дәү бүләк энемә булды —
ул тәпи китте.

## Мактанчык

Карточкага төшәбез —
«Полороид» «чык» та «чык» —
Инде сурәт тә әзер,
Менә карыйбыз хәзер.
Һәммәбез дә әйбәт чыккан,
Энемнең авызы ачык.
Әти көлә: «Мактанчык!»
Шулай диме, ни дисең.
Нәни генә булса да,
Биш ай гына тулса да,
Күрсәтергә уйлаган бит
Әле кичә генә чыккан
Бердәнбер шушы... тешен.

## Гүзәл

Гүзәл дигән гөл утырткан
Әби тәрәз төбенә.
Язлар җиткәч, бу матур гөл
Шау чәчәккә күмелә.
Гүзәл дигән гөл булмый бит,
Кыналар була, яран.
Менә кызык, әбиебез
Ул гөлне кайдан алган?
Гүзәл дигән бу гүзәл гөл
Үсә тик бездә генә.
Ник алаймы? Серен әйтәм,
Белегез сез дә менә.
Гүзәл исемле кыз биргән
Ул гөлне бүләк итеп.
Әби гөлгә Гүзәл кушкан,
Тормаган исе китеп.
Бу хәл булган бик күптән,
Инде Гүзәл дә үскән.
Гөлләр яратучы кызның
Исеме гөлләргә күчкән.



## Дәрҗия

Безнең өйдә кунак бар —
Нәни генә тутый кош.
Зәңгәрсу күлмәк кигән,
Әйтерсең лә тәти кыз.
Исемнең дә без аңа
Куштык иң-иң матурын.
Хәзер өйдә Дәрҗиягә
Калмады бер ят урын.
Чишмә суы гына эчә,
Махсус җим генә ашый,
Баштүбән торып читлектә
Гимнастика да ясый.
Әтием аңа карый да
Мыек астыннан көлә:
— Юкка Дәрҗия түгел бу,
Үз дәрәҗәсен белә.

## Энемә

Әйдә, энем, елмай әле,
Инде ела әзрәк.
Ни әйтсәң дә бүген син
Кичәгедән дәүрәк.

Ә инде дәү кешегә
Елап тору килешми.
Синдәй егет кешегә
Елап тору ул эшме?!

Әйдә үс, үс тизрәк —
Миңа әйбәт дус кирәк.



## Бабай белән малай

Бабаем борынгы кеше,
Энем әле өр-яңа.
Тешсез авызлары белән
Берсе уйлап,
Берсе уйнап,
Елмаялар дөньяга.
Ап-ак бабай,
Ап-ак малай —
Икесе дә сөйкемле.
Арадагы 91 ел
Булмаган да шикелле.

## Син киткәч

Син киткәннән бирле, энем,
Өйнең дә яме бетте.
Гүя бар нур синең белән
Әбиләремә китте.
Өйгә керәсе дә килми
Синең көлү булмагач.
Бар дөнья тынып калган кук
Син тыпырдап тормагач.
Сиңа дип конфет калдырдым,
Ул тора суыткычта.
Иң матур уенчыгымны
Бирермен син кайткач та.
Бүтән бер дә елатмам,
Уйнатырмын үзеңне.
Киреләнсәң дә көйләрмен,
Булырмын гел түземле.
Кайтыр чагыңны көтәм мин,
Көннәрне саный-саный.
Сагынып көтеп алыр өчен,
Энең булу да ярый.

## «Тәмле»

Әни аны ярата,
Гел, «Баллым!» диеп сөя.
Әти, «Алмам» дия-дия,
Түшәмгә чаклы чөя.

— Бигрәк тәмле шул,—
диеп,
Әби дә тора үбеп.
Ә энем ята ишетеп,
Ә энем ята күреп.

Аннан тәмен белер өчен,
Бармагын кабып карый.
Әбием кырын карый,
Әтием бармак яный.

Карап тора да энем
Үпкәләп, елый башлый.
— Үзегез тәмле, дисез бит,
Тәмле миңа да ошый.



## Кемне?

— Кемне яратасың? — диеп,
Миннән һаман сорыйлар.
Бик беләселәре килә,
Кызык та бу олылар.

Әнине яратам дисәм,
Үпкәләр шул әтием.
Миңа китап укымас ул,
Шуңа күрә әйтмимен.

Әтине яратам дисәм,
Әниемне жәллим бик.
Нигә инде бәйләнәсез,
Әйттем бит, юк, әйтмим, дип.

Тәртипсез бу кыз димәгез,
Дорфалык юк сүземдә.
Кемне ныграк яратканны
Белмим әле үзем дә.

## Рәхмәт

Китабымның иң кызыклы
Битенә җиткән идем,
Әни: «Энеңнең чалбары
Сүтелеп киткән»,— диде.

Һаман шундый безнең әни,
Гел боза минем эшне.
Әйтерсең өйнең бар эшен
Мин эшләргә тиешле.

Карышып тору файдасыз,
Энә белән җеп алдым.
Ертылырга гына торган
Чалбарга ямау салдым.

Сеңелемнең күлмәгенә
Матурлап сәдәп тактым.
Ашарга пешереп куйдым,
Әтием эштән кайтты.

Керә-керешкә елмая,
— Лагерьга барырсың,— ди, —
Өй мәшәкатьләреннән
Ял итеп алырсың,— ди.

Әй, шәп безнең лагерьда
Уйныйбыз да, җырлыйбыз.
Кызынабыз, су керәбез,
Бер минут тик тормыйбыз.

Шунысы гына шәп түгел —
Юк бередә әниләр.
Шуңадырмы, күп кызларның
Өйгә кайтасы килә.

Эшкә өйрәнмәгән алар,
Туры килә кыенга.
Минем өчен эш — рәхәт,
Бер кызык уен гына!

Шунлыктан исем дә китми,
Аларга ярдәм итәм.
Үзем сиздермичә генә
Кайтасы көнне көтәм.

Кызганмыйча бөтен көчен,
Эшкә өйрәткәне өчен,
Өйгә генә кайтыйм менә,
Иң-иң әйбәт әниемә
«Рәхмәт!» диярмен әле,
Башым иярмен әле.



# Авылны сагынганда






# Манзара

Матур апа судан кайта,
Чиләкләрен тутырган.
Ап-ак бабай бүрек киеп,
Бүрәнәгә утырган.
Каз бәбкәләре мәш килә
Әниләре янында.
Малайлар балык тоталар
Нәни инеш ярында.
Көн бик эссе, бәтиләрнең
Башы түбән иелгән.
Тырыс тотып күрше кызы
Чыгып килә өеннән.
Барысы да якын миңа,
Бөтенесен дә таныйм.
Агач кимергән кәҗәгә:
«Ярамый!» — диеп яныйм.
Телевизордан күрсәтмиләр
Мондый әйбәт киноны,
Авылым тәрәзәсеннән
Күрдем бүген мин аны.
Утырдым менә күзәтеп,
Тәрәзәне киң ачып.
Карашымнан бер нәрсә дә
Калалмады һич качып.
Телевизорың, видигың
Торсын әле бер якта,
Авылым тәрәзәләре,
Сез исән булган чакта.

## Кыярлар нигә саргайган?

Бигрәк тә эшле инде
Гаиләдә барчабыз да.
Вакыт таба алмыйбыз
Барырга бакчабызга.
Беркөн барып карасак
Бакчабызны, шаккаттык —
Бер кыяр түтәленнән
Өч чиләк кыяр таптык.
Ләкин хикмәт: һәммәсе —
Яшел түгел, сарылар.
Сары күзләрен багып,
Үпкә белән карыйлар.
Без югында үскәннәр,
Безне зарыгып көткәннәр,
Бигрәк каты көткәннәр,
Саргаешып беткәннәр.
Карадым кыярларга,
Бирелдем хыялларга.
Дәү әни искә төште.
Ул да кыярлар төсле...



# Белмәгәч

Күршебезгә бер малай
Кунакка кайткан.
Уйнаганда, болыннан ул
Бер бөҗәк тапкан.
«Камка бабай»ны иелеп
Алды кулына.
Такмаклады ап-ак җәймә
Җәеп юлына.
Камканың шул исе китми,
Берни ишетми.
Гүя шәһәр малаен ул
Үзенә иш итми:
Мыегын да, канатын да
Һич тә селкетми.
Мин кулыма алган идем:
— Камка, кач,— дидем, —
Балаларың көтә сине,
Алар ач,— дидем.
Канатларын җилпеде дә
Китте ул очып.
Карап калды кунак малай
Авызын ачып.
Үпкәле шәһәр кунагы —
Елмаймый, көлми.
Безнең авыл камкасы ул,
Урысча белми.



## Бичура

Никтер безнең мичебезнең
Килми бугай янасы.
Картайгандыр бу мичебез,
Кирәк, димәк, яңасы.
Мич сүтәбез, кирпечләрен
Берәм-берәм кубарып.
Өйгә акшарлар туздырып,
Тузан, корым чыгарып.
Энем көтә Бичураны,
«Мич эченнән чыгар»,— ди.
Әти көлә: «Юк, кирәкми,
Күрсәң, котың чыгар»,— ди.
Мич сүтәбез, корым гына
Кулларым, битем, күзем.
Әкияттәге Бичурага
Охшап калганмын үзем.
Арыган энем көтеп,
Күрсәтә миңа төртеп:
— Таптым шул, ура, ура!
Әнә бит ул — Бичура!

## Авылны сагынганда

Кыңгыраулы бозауны
Авылда күргәнем бар.
Муенынннан кочаклап,
Өстендә йөргәнем бар.

Кыңгыраулы булса да,
Бозау түгел урындык.
Нигә безнең фатирда
Чын бозауга урын юк?

Ә шәһәрдә бозау юк,
Ләкин бар бит... урындык!
Аңа кыңгырау тактым,
Менеп утырып «чаптым».

Соравыма җавап юк,
Шунысы — авыр.
Урындыгым чың-чың елый —
Сагындыра авыл...

# Үрдәк зары

Үрдәк кайта көчкә атлап,
Үрдәк әйтә: «Бак-бак-бак,
Күлдә балык вак-вак-вак,
Ач калмадым чак-чак-чак.
Ә эресе кая киткән?
Нигә күлнең суы кипкән?
Җавап тап-тап-тап!»
— Басуларны ашлаганнар,
Күлгә пычрак ташлаганнар.
Күлнең моңа кәефе киткән —
Суы беткән, корып кипкән.
Күп балыклар үлеп беткән,
Калганы да бик вак икән.

Моны ишетү үрдәкләргә
Бигрәк моңсу, бик күңелсез.
Бәлки әле шушы күлгә
Ярдәмгә сез килерсез.
Белеп торам, сез бит алай
Шәфкатьсезләр түгелсез.
Рәхмәт әйтер үрдәкләр дә,
Менә үзегез күрерсез!



# Зонтик тотып җырлаучы шәһәр кызына авыл малаеннан ачык хат

Телевизордан күрәм сине —
Чыгасың да басасың.
— Яңгыркаем, яу-яу! — диеп,
Зонтигыңны ачасың.
Зонтигың матур, чәчәкле,
Җырлавың да бигрәк шәп.
Ләкин сиңа яңгыр нигә?
Аңлат шуны әйбәтләп.
Синең зонтигың яңа дип,
Гел яңгыр яусынмыни?
Иген кырлары, басулар
Сазлыкта калсынмыни?
Шәһәрдә беләм, рәхәт,
Яуса да яңгыр коеп,
Туфли белән йөреп була,
Буялмый аяк, оек.
Бездә бераз сибәләсә,
Трактор кирәк үтәргә.
Туры килә атна буе
Җир кипкәнен көтәргә.
Яңгыр файдалы, беләм мин,
Яуса вакытын белеп.
Яңгыр башын катырма син,
Зонтигың тотып, көлеп.
Яңгыр бит ул үзе белә
Кайчан, кайда явасын.
Кунакка кайтсаң, суларбыз
Авылның саф һавасын.
Мактаганны кем яратмый,
Чакырганда кем килмәс?
Көннәр буе яңгыр койса,
Күктә бит кояш көлмәс.
Яңгыр ишетсә бу җырны,
Кояр, бер дә туктамый.

Иртән явар, көндез явар,
Хәтта төнлә йокламый.
Телевизордан чыкканыңны
Белсәң ничек көткәнне.
Ләкин башка җырлар җырла,
Матур җырлар беткәнме?
Менә шундый хатлар яздым
Зонтик тоткан кыз, сиңа.
Акыл өйрәткән дип, зинһар,
Ачуланма син миңа.
Мондый хат язарга миңа
Кушты иген кырлары,
Кушты җиләкле аланнар.
Мин сүзләрен тыңладым.
Сау булып тор, инде синнән,
Шәһәрдән хатлар көтәм.
Авыл сәламнәре белән,
Агроном улы — Рөстәм.

## Көзге җыем

Бәрәңге алырга кайттык
Быел авылга.
Җирдән бәрәңге казуы
Бигрәк авыр ла.
Әби аны үзе генә
Ничек соң эшләр?
Картайгач бит, егәр кими
Һәм бетә көчләр.
Шуңа күрә ярдәмгә дип,
Менә без кайттык.
Бер бакча бәрәңгеләрен
Алдык та аттык.
Әй, юк инде, атмадык ла,
Салдык капчыкка.
Ә аннары базга салдык,
Авызын ачтык та.

Иң дәүләре, эреләре
Китәр Казанга.
Алар төшә Казандагы
Безнең казанга.
Андыйларга билет бирдек
Калага, диеп.
Сөенечтән алды алар
Сикереп, биеп.
Үсми калган бәрәңгеләр
Бик көнләштеләр,
«Берәр чара табыйк»,— диеп,
Әй, киңәштеләр.
Нишләсәң дә булмый инде,
Быел эш үткән.
Әнә башлы бәрәңгеләр
Ничек зур үскән.
Киләсе елга болар да
Һич алдатмаслар.
Казанга алар барырлар,
Базда ятмаслар.
Һәрберсе булыр аларның
Йодрык кадәрле.
«Киләсене көтү озак,
Бүгенгә — гарьлек».
Бәрәңгеләрнең сүзләрен
Тордым мин тыңлап.
Әгәр аларның уйлары
Булсамы чынлап...
Чакырам сезне авылга
Киләсе көзгә.
Калага алып китәрсез
Аларны сез дә.




# Песи сагынуы

Песи авылда туган,
Песи авылда торган.
Авылда чагында ул
Тычканнарны күп кырган.
Язмыш шулай кушкандыр,
Песи килгән калага.
Тере уенчык булган
Ялгыз үскән балага.
Урамга чыгармыйлар,
Юк күсе дә юк тычкан.
Кыен — авылда туып,
Аннан шәһәрдә торсаң.
Бик тәмле ашаталар,
Гел затлы ризык кына.
Ләкин песи фатирда
Табалмый кызык кына.
Битарафка әйләнде,
Берничә исе китми.
Ник дөньясы ишелми,
Мыегын да селкетми.
Эреп төшми мактауга —
Чыкты ата ялкауга.
Йокы — бар белгән эше,
Аптырый күргән кеше.
Сагынудан йончыды,
Гел йоклый шуңа күрә.
Йоклаганда төшендә
Туган авылын күрә!



## Аппак

Песиебезнең исеме
Үзе шикелле — Аппак.
Шуңа кышын урамда
Йөртәбез аны саклап.
Кар да ап-ак, песи дә,
Югалтуы бик җайлы.
Аннан аны табар өчен
Көтәсе булыр җәйне.



## Печән өсте

Печән өсте хуш исле,
Җир җиләкләре төсле.
Бер болынны берүзе
Чапты әти, ай, көчле.
Әти чапкан ул печән
Бер кибән булыр тиздән.
Җырлап торган чалгысы
Тип-тигез итеп тезгән.
Мин үзем дә тик тормыйм —
Чапкан печәнне тырмыйм.
Печән өсте авылда.
Эше күп тә, авыр да.
Аның каравы, кышка
Печән булыр лапаста,
Бик күп булыр запаста.
Аны ашар да сыер,
Мул бирер тәмле сыен.
Килеп торыр ул сөтне
Эчкән саен эчәсе.
Килеп торыр ул сөттән
Җир җиләкле җәй исе.

## Карга боткасы

Җиребезгә язлар килгәч,
Кошлар кайткач еракtan,
«Карга боткасы» пешергән
Халкыбыз чын йөрәктән.
Бу бәйрәм безнең көннәргә
Килгән гасырлар үтеп.
Каргалар да, без дә аны
Һәр ел алабыз көтеп.

Быел да менә пешердек:
Салдык тәмле ярмалар,

Сыйланыгыз, туган якны
Сагына белгән каргалар!
Изге йола еллар кичеп,
Киләчәккә дә барсын.
Үз боткаларын ашарга,
Берүк, каргалар калсын!

## Алданган кыш

Алмагачлар чәчәк ата
Урталарында майның.
Шулчак кинәт салкынайта —
Хикмәте бар бу айның.
Тәрәздән карап тордым да
Ясадым нәни ачыш.
Ак чәчәкне кар дип белеп
Сөенеп куйгандыр кыш.
Кабат киләм, диеп уйлап,
Салкын капчыгын чишкән.
Шуңа суытып җибәргән,
Котып җилләре искән.
Ә чәчәкләр курыкмыйлар,
Бик горур утыралар.
Таҗларының эчләренә
Җимешләр тутыралар.
Кышның алданганын күреп,
Кояш елмая, көлә.
Ул бит белә — табигатькә
Кыш түгел шул, җәй килә.



# Яз

Гөрләвекләр җыр чыгара
Язны сәламләп, беләм.
Кояш күктә шигырь яза,
Алтын каләме белән.
Кошлар кайткач, ул шигырьне
Бик сөенеп ятларлар.
Җәйләр буе сайрый-җырлый
Һәр көнне кабатларлар.
Шуңа кояш бик тырыша —
Матур булсын җәйге җыр.
Урамда яз, табигатькә
Илһам килгән ямьле чор.



# Мин ясаган ачышлар





## Бур буран

Карамадым әнинең:
«Чыкма!» — дигән сүзенә.
Нәни малай түгелмен,
Хуҗа мин үз-үземә.
Кичә урамда йөрдем,
Кичә буранда йөрдем.
Суык диеп тормадым —
Сызгырдым һәм җырладым.
Ә менә инде иртән
Тавышым кая киткән?
Авызны ачам, ябам —
Тавыш кына юк һаман.
Әни белә сәбәбен,
Әйтерсең күреп торган.
— Улым,— ди,—
тавышыңны
Урлаган синең буран.
Авыз ачып йөргәнсең,
Җырлагансың, көлгәнсең.
Тавышың калган урамда,
Урамдагы буранда.

Бүген мин өйдә торам —
Бер эсселим, бер туңам.
Минем тавышым белән
Урамда җырлый буран.
Тәрәз аша карыйм да
Кычкырамын буранга:
— Урлашу начар әйбер,
Тавышымны кире бир!

Буран миңа карый да,
Буран мине таный да,
Җил-бармагын яный да,
Карлар өя бер олау.
Карашында бар сорау:
— Йә ничек, әйбәтме,—
ди, —
Әни сүзен тыңламау?



# Вакыт җитми



Урамга чыга идем,
Ботинкамны да кидем.
Тик бавын бәйли белмим.
— Өйрәнче,— ди әнием.
— И әнием, әнием,
Кайчан өйрәним ди мин,
Иртән бакчага чабам,
Ә кичкә арыйм тәмам.
Әгәр белсәм, дөньяларым
Китәр иде көйләнеп.
Юк шул, булмый, ял көне дә
Булмый әле өйрәнеп.
Өйрәнәм диеп тотынсам,
Озак көтәр бит энем.
— Көттерү яхшы түгел
Кешене,— ди әнием!
— Энем мине озак көтәр,
Киенгән ул, тирләп бетәр,
Суык тияр, чирләп китәр...
— Ярар инде, ярар җитәр...
— Юк, көтмәсен инде энем,
Чирләмәсен инде энем.
Ботинкамның бавын гына
Бәйләп бирче, әнием.
Үземнең дә килә инде
Өйрәнәсем, беләсем бик.
Мин гел ялкау малай түгел,
Вакытым юк, беләсең бит.



Рәхмәт инде ак карга:
Рәхәт иде ул барда.
Бөтен дөнья ак иде,
Чиста иде, пакь иде.
Инде менә яз килде,
Эреп акты юрган-кар,
Чыкты аның астыннан
Өеме белән чүп-чар.
Урамнар шундый шапшак —
Атлап йөрибез чак-чак.
Көздән беркем җыймаган,
Җыярга уйламаган.
Без, ялкауларны, күреп,
Кар яуган, куйган күмеп.
Көзен эш күпне белгән,
Безгә ярдәмгә килгән.
Инде менә кар бетте.
Чүпне җирдән үзебезгә
Җыярга вакыт җитте.
Әгәр тагын җыймасак,
Күреп шушы чүп-чарны,
Бәлки, кабат каплап китәр,
Белеп булмый бу карны...
Юк инде, кар кирәкми,
Алдык кулга көрәкне,
Икенчесенә тырма —
Эшлә син дә, тик торма!
Эшли әби-бабайлар,
Эшли әти, малайлар,
Нык тырышалар бар да —
Эш калдырмыйк, дип карга!



# Башлы бәрәңге

Башлы кеше була инде,
Башлы суган барын беләм.
Телисезме, таныштырам
Башлы... бәрәңге белән.
Әйе, әйе, күргәнем бар,
Дәү ул, йомры гәүдәле,
Ак тәнле, юка кабыклы,
Җитмәсә әле тәмле.
Мактый-мактый ашыйбыз —
Бик тәмле иткән ашны.
Ни дисәң дә бу бәрәңге
Башлы шул инде, башлы.

# Карарбыз сагынганда

Бик матур бер кышкы көнне
Ясадык без Кар бабай.
— Өйгә алып керик,— ди бит
Энем, үзсүзле малай.
— Энем,— димен,— үскәнем,— дим, —
Ничек булсын ул алай?
Өйгә керү белән суга
Әйләнер бит Кар бабай.

Бер киреләнә башласа,
Энемнең үз туксаны.
— Уйнап туйгач, суыткычка
Куярмын,— ди,— мин аны.

Кар бабай безнең бәхәсне
Тыңлап тора, эндәшми.
Ярый әле, башлы әти,
Җаен тапты бит тәки.
Өчебезне дә бергәләп
Ул рәсемгә төшерде.
Кар бабай да матур чыккан:
Ул чиләге, кишере.
Хәзер инде Кар бабабыз
Һәрвакыт безнең янда.
Язлар җиткәч тә карарбыз
Без аны сагынганда.





## Колаклы коймаклар

Апам коймак пешерде
Беренче тапкыр.
Коймаклары шундый тәмле
Һәм шундый... матур.
Майлы һәм баллы булганга
Яраттык коймакларны.
Ләкин алар гади түгел,
Бар нәни колаклары.
Кайсында биш, кайсында өч,
Кайберләрендә алты.
Колаксызлар бөтенләй юк,
Берсе ярты колаклы.
Майга буялды бармаклар,
Иреннәр, колаклар да.
Үзебез дә охшап калдык
Колаклы коймакларга.

# Көйсез көн

Онытканмы табигать
Урамда май икәнне,
Белми микән ул безнең
Җәйне сагынып көткәнне?
Җилләрнең суыклары
Җаннарга тула инде,
Күңелләребез боек,
Мөгаен, шуңа инде.
Кара бүгенге көнне —
Әллә ниләр итенде:
Кар яуды, яңгыр койды,
Аннары кояш көлде.
Әни әйтә: «Быелгы яз
Сиңа охшаган, кызым,
Син дә көйсезләнәсең бит,
Тыңламыйсың көнозын.
Бер елыйсың, бер көләсең,
Көеңне булмый табып...»
Әни әйткәч, көйсез көндә
Үземне алдым танып.
Бүтән көйсезләнмим инде,
Сорамагыз: «Нигә?» «Ник?»
Хәзер көтәм май да миннән
Кайчан үрнәк алыр дип.
Аның бит кабаттан миңа
Охшыйсы килер әле.
Димәк, тиздән, озакламый
Җылы җәй килер әле.



## Ятимә

Бөдрә тунлы бәтигә
Исем куштык — Ятимә.
Әнисез ул, ятимә.
Ул бәтигә син тимә.
Ул болай да ямансу,
Күзләре аның моңсу.
Тамагы тук булса да,
Елый ул төне буе,
Эзли ул җылы куен —
Әнисенең ак тунын.
Әнисез шул бик кыен.
Ятимлекнең ачысын
Нәни бәти беләдер.
Аның да бит әниле
Буласы бик киләдер.
Кызгандым, Ятимәнең
Күргәч тә моңсу күзен.
Тыңларга булдым үзем
Әниемнең бар сүзен.

## Белмәмеш

Мин — Белмәмеш, Белмәмешне
Юктыр белмәгән кеше.
Белмәмеш булган малайның
Бик ансат аның эше:
Әниең эш кушкан саен,
«Белмим»,— дип тик торасың,
Ә үзең сиздерми генә
Төрле хәйлә корасың.
Ботинкаларың бавын да
Бәйли белмәсәң әгәр,
Өйгә файда китермәсәң
Тузан бөртеге кадәр, —
Шундый була Белмәмеш.
Ләкин миннән көлмәгез!
Мин бит әле бик нәни,
Үзе шулай ди әни.
Үсәрмен, өйрәнермен,
Белмәмеш булмам һаман.
Акыллы Беләмәнгә
Әйләнермен берзаман.
Менә күрерсез!

# Туп үпкәсе

Минем матур тубым бар —
Кызыллы, аклы, зәңгәр.
Беркөн миңа үпкәләде.
Ялганламыйм, чын әгәр.
Көн яңгырлы, пычрак иде,
Суык иде, җитмәсә.
Үпкәләмәс тә иде ул,
Дәү малайлар типмәсә.
Бар гаеп үземдә минем,
Ник өйдән алып чыктым?!
Кулымнан алып типтеләр
Үзәгенә балчыкның.
Тубым минем ерак китте,
Сизеп тордым — елап китте.
Йөгереп бардым,
Иелеп алдым.
Туңган иде, буялган,
Хәтта бөрешеп калган.
Аңа бит ярдәм кирәк,
Өйгә йөгердем тизрәк.
Җылы су белән тубымны
Әйбәтләп юдым башта.
Аннары гафу сорадым:
«Усал малайлар кулына
Бирмәмен,— дидем,— башка».
Билгеле инде, гафу итте,
Билгеле инде, кичерде,
Йөзләре яктырып китте,
Әллә каян көч керде.
Дусларыңны үпкәләтсәң,
Үземнән беләм — кыен.
Тубым да шат, мин үзем дә,
Күңелле бүген уен.

Уен булмый хәрәмсез,
Уен булмый үпкәсез,
Шуңа футбол уенын
Санамагыз чүпкә сез.
Футбол тубы карбыз булса...
Вәт уйнар идем футбол.
Әти көлә: «Андый туп
Бөтен дөньяда юктыр».
Әллә соң бармы икән?!
Мин бит хыялда йөртәм.
Әгәр андый туп булса,
Капкама үзем кертәм.
Әгәр шулай типкәндә,
Ярылып та китсәме?
Малайларны сыйлармын
Онытып бар үпкәне.
Җиңелгән дә, җиңүче дә —
Карбыз ашар һәммәсе.
Карбыз белән үпкә бетәр,
Кызык булыр хәйләсе.
Исәпне тигезлик диеп,
Тагын уйныйкмы дисәк,
Менә кызык, туп-карбыздан
Калган бары бер кисәк.
Футбол тубы карбыз булса,
Вәт уйнар идек футбол...
Юк шул, уйный алмас идек,
Ярый андый туп юк ул.



# Светофорга мәдхия

Без мәктәпкә барабыз
Иртән, ашыга-ашыга.
Машиналар ашыга,
Килеп чыга каршыга.
Ярый әле, шул чакта
Светофор тора чатта.
Ярый әле, ярый әле,
Светофор тора сакта.
Җемелдәтеп өч күзен
Әйтеп сала өч сүзен.

Кызыл әйтә: «Туктап кал!»
Сары әйтә: «Игътибар!»
Яшел әйтә: «Юл ачык!
Карап кына атлап чык».

Әмма ләкин бар чатта
Светофор тормый сакта.
Юл аркылы чыгулар
Мең газап ла бу чакта.
Без бергәләп җырлыйбыз
Бүген сезгә шул хакта.
Урамнарда һәр чатта
Светофор торсын сакта.
Җемелдәсен өч күзе,
Әйтеп салсын өч сүзне.

Кызыл әйтсен: «Туктап кал!»
Сары әйтсен: «Игътибар!»
Яшел әйтсен: “Юл ачык!
Карап кына атлап чык».

Әй, сез, өлкән абыйлар,
Безнең хәлгә керегез.
Олы юллар чыкканда,
Имгәнмәсен беребез.

# Тылсымлы сүзләр



Иртән әни уята:
— Улым, хәерле иртә!
Шул тылсымлы сүз мине
Көн буе саклап йөртә.

Әби мәктәпкә озата:
— Улым,— дип,— хәерле юл!
Әбием изге күңелле,
Гел хәерле була юл.

Мәктәбемә баргач та
Телимен: «Хәерле көн!»
Әллә шуңа әйбәт кенә
Хәерле уза бу көн.

Кичен әти каршы ала:
— Хәерле кич, улым,— дип.
Бергәләшеп уйнаганда
Хәерле уза кич бик.

Гап-гади инде үзләре,
Катлаулы түгел һични.
Әмма хәерле итәләр
Иртәне, көнне, кичне.



Мин шушындый сүзләр беләм.
Син дә беләсең микән?
Хәерле юл! Хәерле көн! —
Тылсымлы сүзләр икән.

## Солтан булдым

Беркөн шулай солтан булдым.
Юк, төштә түгел, өндә.
Ләкин солтан булулары
Җиңел эш түгел бер дә.
Озын чапан киеп алдым,
Башка чалма бәйләдем,
Тәхеткә менеп утырдым —
Мин солтанга әйләндем.
Борын азрак күтәрелде,
Биреп утырам әмер.
Әйтерсең мин Айдар түгел,
Бер бөек хан йә әмир.
Илне идарә итүе
Бигрәк кыен эш икән,
Әллә солтан булганнарга
Ике баш тиеш микән?!
Чынлап солтан булучыга
Ходаем бирсен түзем.
Ярый әле, азга гына
Солтан булдым мин үзем.
Шөкер әле, ярый, димен,
Чынлап солтан булмадым.
Мәктәп сәхнәсендә генә
Артист булып уйнадым.

## Кунакка килегез!

Кунакларны бик яраткан
Электән безнең халык.
— Юмарт,— диеп,— уңган,— диеп,
Килгән күптән макталып.

Татар кызы — Таңсылу мин,
Уңган буласым килә.
Чәем кайнар, чәкчәк әзер,
Йә, кем кунакка килә?!



## Сәлам, галәм!

— Алло, алло, Марсмы бу?
Хәбәр бирәм мин Җирдән.
Бу мин — Айнур атлы малай,
Татарстан дигән илдән.
Бездә инде көзләр җитте,
Ә сездә анда ничек?
Салкын җилләр исәләрме,
Яңгыр явамы ишеп?
Марс малайларының да
Борыннары кызылмы?
Ә буйлары минем кукме?
Йә, азрак озынмы?
Бик күрәсем килә сезне,
Төшегез әле, әйдә!
Ара ерак булса да,
Яшибез бер галәмдә.



## Шагыйрь абыйга

Муса абый, шигыреңне
Ятладым бик яратып.
Сөйләдем аны һәммәсен
Авызыма каратып.
Әни сине үлгән, дигәч,
Күзләремә яшь килде.
Минем үскәнне көтмәдең,
Муса абый, ник инде?
Әгәр көтсәң, сугышка да
Без икәү китәр идек,
Икәү булгач, мең фашистның
Башына җитәр идек.
Ул чагында тоткында да
Булмас идең, мөгаен.
Чөнки сине коткаруның
Табар идем мин җаен.
Көткән булсаң мин үскәнне,
Юк, булмас идек харап.
Шулай уйлап торам менә
Таш һәйкәлеңә карап.

## Ни эшләрмен?

Әни: «Тешләрең ю!» — дигәч,
Киреләндем, «Юк!» — дидем.
Бик юар идем дә хәзер,
Тик тешләрем юк минем.
Иртән-кичен юар идем,
Тәмле пасталар белән...
Мин, кире малайдан, тешләр
Качтылар берәм-берәм.
Ә менә бит-кулны юам,
Сөртәм хәтта сабын да.
Алары да ташлап качса,
Нишләрмен ул чагында?!

## Бары «Сабантуй» белән

Аның белән танышсаң,
Һәр көнең булыр бәйрәм —
Шигырьләр, әкиятләр
Аңарда бәйләм-бәйләм.

К у ш ы м т а:

Мин шундый гәзит беләм.
Сез дә беләсез, беләм.
Балачаклар ямьле була,
Ә гомерләр гамьле була
Бары «Сабантуй» белән!

Әгәр ныклап дуслашсаң,
Булырсың зирәк, тапкыр.
Ул сиңа кунакка килер
Елга 104 тапкыр.

К у ш ы м т а.

Туган телне сөярсең
Дуслашсаң үзе белән.
Киңәшләр дә бирер ул
Ягымлы сүзе белән.

К у ш ы м т а.

Уйларга ул өйрәтер,
Укуда ярдәм итәр.
Әйбәт малай, кыз булырсың,
Даның еракка китәр.

К у ш ы м т а.



# Васыять

Еллар саргайткан кәгазьне
Сак кына кулыма алам.
Әбиемә васыять язган
Соңгы хатында бабам.

Язмаган ул көт мине, дип,
Әйтмәгән көтмә, дип тә.
Әйткән бары: «Балаларны,
Зинһар, итексез йөртмә.

Туган-үскән җирләренә
Бассын алар нык итеп.
Өшемәсен аяклары,
Зинһар, ала күр итек».

Туплар шартлаган чакта да
Уйлаган шушы хакта.
Ата сөюе сакланган
Еллар үтсә дә хатта.

Үзен ни көткәнен белгән —
Сугышлар бара каты.
Ул үзе кайта алмаган,
Кайткан бары шул хаты.

Күзләремне яшьләндерде
Шушы соңгы сүзләре:
«Аяклары исән булсын,
Җирдә калсын эзләре».

Моннан да изге теләкне
Тагын кем тели алган?
Ятим калгач, әтиләрне
Васыять саклап калган.

# Шигырь

Шигырь язарга утырдым.
Җиңел эш түгел бер дә.
Өстәлдәге дәфтәремдә
Сүз түгел, юк өтер дә.

Язам дигәч, язамын,
Рифмасын да табамын.
Күрше кызы Гөлсинә
Шаккатсын әле менә.

Күптәнге «2»лемне
Онытмый ни гомергә.
Көлүеннән йөрәгем
Калды кара күмергә.

Бу әбием сүзләре
Таман килә миңа да.
Күршеңдә ут кыз булса,
Кыен яшәү дөньяда.

Әй лә, читкә кителде.
Әллә болай итимме?
Башлап китәргә ничек?
Шулчак ачылды ишек.

Чакыра кергән Гөлсинә,
Ул йөзләре — гөл сибә!

Күрше кыз эндәшкәнгә,
Оныттым бар дөньямны.
Шигырьнеме? Шигырьне
Барыбер язам мин аны.

## Минем әни

Әни белән бик рәхәт тә,
Бакчага барасы бар.
Ул киткәндә тәрәзәдән
Кул болгап каласы бар.

Мин дә иртән эшкә китәм —
Бакчада минем эшем.
Барам, кичен әниемне
Сагынып кайтыр өчен.

## Алдау уены

Алдау уены уйныйбыз,
Алдый белә һәммәбез.
Ялганлыйбыз — ышаналар,
Оста булгач хәйләбез.
Маратны да алдадык без:
— Әнә әтиең кайта!
Сикереп торып чабып китте
Ул без күрсәткән якка.
Өметләнеп йөгерде ул
Әтисенең каршына.
Эх, сизмичә кагылганбыз
Йөрәге ярасына.
Маратның шул әтисе юк.
Киткән ташлап, калдырып,
Нәни улы йөрәгенә
Сагыш уты яндырып.
Инде кайтып килә Марат,
Адымнар салмак, сүлпән.
Ул бу юлы гафу итсә,
Алдамас идек бүтән.
Алданганнан көлә идек,
Ә Мараттан — көлмәдек.
Үксеп елый — ничек итеп
Юатырга белмәдек.

# Әбиләр мәктәпкә бара

Әбиләр мәктәпкә бара,
Авыр сумкалар кулда.
Туктап хәл дә сорашмыйлар
Мәктәпкә илткән юлда.
Берәү, икәү, өчәү... унау.
Һәммәсе дә ашыга.
Кайберләре кайтып килә —
Очрыйлар каршыга.
Бу хәлне күзәтеп торсаң,
Бер елап, бер көләрсең?
Әбиләргә махсус мәктәп
Ачканнар дип белерсең.
Онықлары янда гына,
Кулларында — туңдырма.
Чынбарлыкта булган хәл бу,
Түгел шаян уйдырма.
Оныкларын саклый алар:
Яшьтән җәфа күрмәсен,
Авыр сумкалар күтәреп,
Газапланып йөрмәсен.
Ә әбиләр өйрәнгәннәр
Сөйрәргә тормыш йөген.
Шуңа күрә кулларында
Кабат сумкалар бүген.
Ышанмасаң, әнә үзең
Урамга чыгып кара.
Кулларына сумка тотып
Әби мәктәпкә бара.



## Малай бабай

Дөньяда күп малайлар,
Дөньяда күп бабайлар.
Сирәк кенә булса да,
Була малай бабайлар.
Бабай диеп аларны
Булмыйдыр, бәлки, атап.
Ул чагында аларга
Үзең бүтән исем тап.
Сакаллары ак түгел,
Үзләре дә карт түгел,
Тик исәнлек шәп түгел,
Һәм бик шәп түгел күңел.
Алтмыш та, җитмеш тә түгел,
Ун, унике аларга.
Йөзләренә кызганмыйча
Мөмкин түгел карарга.
Кан качкан йөзләреннән,
Нур киткән күзләреннән,
Кайсы телдә сөйләүләре
Аңланмый сүзләреннән.
Мускул дисәң, ул да юк,
Йөрешләр аю кебек.
Малаймы ул, бабаймы?
Тиз генә булмый белеп.
Исемдә түгел хикмәт,
Аңлатам хәзер иплэп.
Зарядка ни икәнен
Белмәгәннәр, күрәсең.
Кыяфәтләрен күреп,
Бер елап, бер көләсең.
Нигә шулай картайганнар?
Зәхмәтме бу, сихерме?
Тыңласагыз колак салып,
Ачамын сезгә серне.
Көне буе телик-видик
Карап ятканнар алар.

Ята торгач, диваннарга
Берегеп katkannar алар.
Футбол да уйнамаганнар,
Кумаганнар алка да,
Сәяхәткә бармаганнар,
Биштәр асып аркага.
Хәтта утын ярмаганнар,
Күрәмәгәннәр кар да.
Өйдәге эшне эшләргә
Әти-әниләр бар ла!
Көн артыннан көн үткән,
Нәтиҗәсен беләсез,
Малай бабайны күреп,
Бармак төртеп көләсез.
Бөкреләре булса да,
Алар әле аякта.
Тагын шулай дәвам итсә,
Калачаклар таякка.
Мин алай түгел, дисеңме?
Мин бабай түгел, дисеңме?
Ул чагында чын күңелдән
Котлыйм, дускай, мин сине!



# Әни булдым

Мин — әниемнең кызы.
Минем кызым — курчагым.
Ашаттым да, эчердем дә,
Ни эшлим инде тагын?
Ә ул һаман көйсезләнә,
Йокламый һич кенә дә.
Әйткәнне дә аңламый шул,
Ичмасам, кечкенә лә.
Аның урынында булсам,
Йоклар идем мин күптән.
Тагын азрак көйсезләнсә,
Үзем үк йоклап китәм.
Кызым булгач, мин — әнисен
Ул бит тыңларга тиеш.
Мин бүген шуны аңладым:
Әни булу — кыен эш.



# Эчтәлек

**Безнең өйдә**

Рамазан аенда . . . . . . . . . . 4
Әби хәйләсе . . . . . . . . . . . 5
Әни сүзе . . . . . . . . . . . . . 6
Кыскартканнар . . . . . . . . . . 7
Өйрәтә . . . . . . . . . . . . . . 7
Әйбәт укучы булам . . . . . . 8
Язилә . . . . . . . . . . . . . . . 9
Билге . . . . . . . . . . . . . . . 10
Икәүләшеп укыйбыз . . . . . . 11
Бабай кайтты . . . . . . . . . 12
Энем теле . . . . . . . . . . . . 13
Әби кайда? . . . . . . . . . . . . 14
Үпкә . . . . . . . . . . . . . . . . 15
Урынсызга әрләмә . . . . . . . 16
Көтәмен... . . . . . . . . . . . . 17
Курку . . . . . . . . . . . . . . . 18
Бүләк . . . . . . . . . . . . . . . 18
Мактанчык . . . . . . . . . . . . 19
Гүзәл . . . . . . . . . . . . . . . 19
Дәрҗия . . . . . . . . . . . . . . 20
Энемә . . . . . . . . . . . . . . . 20
Бабай белән малай . . . . . . . 21
Син киткәч . . . . . . . . . . . . 21
«Тәмле» . . . . . . . . . . . . . . 22
Кемне? . . . . . . . . . . . . . . . 23
Рәхмәт . . . . . . . . . . . . . . 23

**Авылны сагынганда**

Манзара . . . . . . . . . . . . . . 26
Кыярлар ник саргайган? . . . . 27
Белми . . . . . . . . . . . . . . . 28
Бичура . . . . . . . . . . . . . . 29
Авылны сагынганда . . . . . . 29
Үрдәк зары . . . . . . . . . . . 30
Зонтик тотып җырлаучы шәһәр кызына авыл малаеннан ачык хат . . . . . . . . . . . 31
Көзге әкият . . . . . . . . . . . 32
Песи сагышы . . . . . . . . . . . 34
Аппак . . . . . . . . . . . . . . . 35
Печән өсте . . . . . . . . . . . . 36
Карга боткасы . . . . . . . . . 36
Алданган кыш . . . . . . . . . . 37
Яз . . . . . . . . . . . . . . . . . 38

**Мин ясаган ачышлар**

Бур буран . . . . . . . . . . . . 40
Вакыт җитми . . . . . . . . . . 41
Калган эшкә кар ява . . . . . 42
Башлы бәрәңге . . . . . . . . . 43
Карарбыз сагынганда . . . . . 44
Колаклы коймаклар . . . . . . 45
Көйсез көн . . . . . . . . . . . . 46
Ятимә . . . . . . . . . . . . . . . 47
Белмәмеш . . . . . . . . . . . . 47
Туп үпкәсе . . . . . . . . . . . . 48
Чынга ашмас хыяллар . . . . 49
Светофорга мәдһия . . . . . . 50
Тылсымлы сүзләр . . . . . . . 51
Солтан булдым . . . . . . . . . 52
Кунакка килегез! . . . . . . . 52
Сәлам, галәм! . . . . . . . . . . 53
Шагыйрь абыйга . . . . . . . . 54
Ни эшләрмен? . . . . . . . . . . 54
Бары «Сабантуй» белән . . . 55
Васыять . . . . . . . . . . . . . . 56
Шигырь . . . . . . . . . . . . . . 57
Минем эш . . . . . . . . . . . . . 58
Алдау уены . . . . . . . . . . . 58
Әбиләр мәктәпкә бара . . . . 59
Малай бабай . . . . . . . . . . . 60
Әни булдым . . . . . . . . . . . 62





Литературно-художественное издание для детей

Йолдыз
*(Шарапова-Замалетдинова Йолдыз Адиповна)*

**Ушастые блины**

(на татарском языке)

Мөхәррире *Р.Х.Корбанов*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *С.Н.Нуриева*
Корректоры *Л.Ш.Шәфыйкова*

Нәшриятка 04184 номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 24.08.2003. Форматы $70\times100^1/_{16}$. Офсет кәгазе.
«Школьная» гарнитурасы. Офсет басма. Басма табагы 5,20. Шартлы буяу-оттиск 6,18.
Нәшер-хисап табагы 3,14. Тиражы 5000. Заказ С-223.

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19.

http://tatkniga.ru
e-mail: tki@tatkniga.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Полиграфия-нәшер комбинаты» Дәүләт унитар предприятиесе.
420111. Казан, Бауман ур., 19.